**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылышның XIX утырышы

05 июль 2024 ел № 18 ш.т. Уруссу б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль законга, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федерал законга, 2007 елның 8 ноябрендәге »Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 257-ФЗ санлы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлек Уставына таянып, 2024 елның 26 мартындагы «Законнарга үзгәрешләр турында»гы 02-01-13/2024 санлы Ютазы районы Прокуроры мәгълүматын искә алып, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге өстәмә кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле «в» абзацы белән тулыландырырга:

«в) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары йөргән өчен түләүне кертү тәртибен үтәү өлешендә транспорт чаралары узуны гамәлгә ашыруга;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча бастырып чыгарырга һәм

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башлыгы- Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Советы рәисе А.Ә. Шафигуллин